СОВЕТ КУРАЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КУРАЛОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

27.09.2017 с. Куралово 27-116

Куралово авыл җирлеге территориясендә гражданнар үзара салым акчалары кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Куралово авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» 2017 елның 18 сентябрендәге 26-113 номерлы Куралово авыл җирлеге Советы карары, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» Куралово авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 18.09.2017 ел № 35 карары нигезендә,

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Куралово авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча 2017 елның 19 ноябренә җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

«2018 елда Куралово авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчалар юлламасы белән риза булырсызмы:

- Куралово авылында урнашкан 1 000 метр озынлыктагы һәм Рус Борнашы авылындагы150 метр озынлыктагы зиратларның коймаларын тотып алу.

ӘЙЕ ЮК".

3. «Волжская новь» район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Куралово авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге башлыгы Л.И.Коткова